СОВЕТ ВЕРХНЕСУБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮГАРЫ СУБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
«22»декабрь 2025 г.

**КАРАР**
№ 16

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында " 03.10.2025 ел, № 66-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Югары Субаш авыл җирлеге Советының 26.04.2021 №23 карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Борнак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә кертергә.
(14.03.2023 № 73, 31.07.2023 №86, 29.11.2024 № 122 үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләр:

- Нигезләмәнең 11 статьясындагы 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен түбәндәге типик квалификация таләпләре билгеләнә:

1) һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: югары белем яисә урта һөнәри белем булу - авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаларның Югары, баш һәм әйдәп баручы төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен;

2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына: муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча-кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча-муниципаль хезмәт яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.

Алып баручы, өлкән һәм кече төркемнәрнең муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына квалификация таләпләре билгеләнми.

Муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларындагы һәм аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәт вазыйфаларындагы һәм башка төр федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларындагы эш стажы да исәпкә алына.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (baltasi.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлеге бүлегендә

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Югары Субаш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Югары Субаш авыл җирлеге А. А. Хөснетдинов